СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　КАРАР

14.10.2022　　　　с. Майдан　　　　22-115

Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләүгә чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставы белән,

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Мәйдан авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 апрелендәге 36-169 номерлы (28.10.2020 ел № 2-18 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советының
2022 ел «14» октябрь № 22-115 карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет сәркатибе | 15904 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советының
2022 елның «14» октябреннән №
22-115 Карарына
12 нче кушымта

Мәйдан авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләре күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 16389 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советының закон һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев